# ЧИШМӘ БАШЫ



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»МБМББУ, апрель, 2025 ел  № 6

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

***1. Милләтемнең горурлыгы – Тукай туган бу айда!***

***2. Республикакүләм Эковесна 2025 бәйгесендә катнашабыз.***

***3. Без космонавт булабыз!***


**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.**



# Милләтемнең горурлыгы – Тукай туган бу айда!

21 апрельдән 25 апрельгә кадәр Мөндеш балалар бакчасында  “Тукай - безнең күңелләрдә!” дип исемләнгән тематик атна булып узды. Балаларда Г.Тукайның иҗатына кызыксыну тәрбияләү максатыннан, төрле чаралар оештырылды. Балалар, тәрбиячеләр белән бергәләп, язучының әкиятләрен искә төшерделәр, шигырьләрен укыдылар. “Тукай геройлары” дигән темага рәсемнәр ясадылар, әдипнең әсәрләрен сәхнәләштерделәр. Шагыйрьнең әсәрләрен өйрәнеп, “Шигырь бәйгесе”ндә катнаштылар. Йомгаклау чарасы буларак, Мөндеш башлангыч мәктәбе белән берлектә “Тукай безнең күңелләрдә” дигән әдәби - музыкаль кичә узды. Кичә барышында шагыйрьнең тормыш юлын искә төшерделәр, Тукайга багышланган шигырьләр укылды, җырлар җырланды.











**_Без республикакүләм “ЭКОВЕСНА” бәйгесендә катнашабыз_**

Конкурс экологик марафон форматында санитар-экологик икеайлык булып үткәрелә.
1 нче атна – “Канатлыларга ярдәм ит” (сыерчык оялары/җимлекләр ясау, шулай ук аларны элү, 1 нче апрельдә халыкара кошлар көне билгеләп үтелә);
2 нче атна – макулатура җыю акциясенә кушылдык. Әлеге акциядә катнашкан балаларга, аларның әни-әтиләренә һәм Мөхәммәдиевлар гаиләсенә чиксез рәхмәтләребезне белдерәбез;
3 нче атна - “Җиргә бакча бүләк ит ” акциясе (яшел үсентеләр утырту, 19 нчы апрельдә “Хәтер бакчасы” халыкара акциясе үткәрелә)
4 нче атна – “Синең гамәлләрең” (бакча территориясен чистарту акциясе)







**12 апрель – Космонавтика көне.**

Бакчабызда бу көнне “Без космонавт булабыз” дигән темага әңгәмә уздырылды.

Әңгәмәнең бурычлары – балаларның кызыксынучанлыкларын арттыру, хәтерләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү. Шулай ук балаларның галәм турындагы белемнәрен системалаштыру бурычлары да куелды.

Әңгәмә барышында балалар космоска кагылышлы сорауларга җавап бирделәр, шушы теманы чагылдырган презентация белән таныштылар. “Космос” исемле ял минутында ракетада очып ял итеп алдылар. Дәрес ахырында балалар ракета кисеп, ябыштырып, үз ракеталарын “галәмгә” очырдылар.









